**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Күтәмә авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396) 4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

---

**№ 158** **19.03.2020**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 28 декабрендәге Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта хупларга һәм гавами тыңлауларга чыгарырга

2. Мәгълүмати стендта урнаштырырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында» әлеге карарын.
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

турында» карары проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибен (3нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә 2020 елның 6 апрелендә 10.00 сәгатьтә Күтәмә авылы, Клуб урамы, 2а йорт адресы буенча авыл Мәдәният йортында.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Уставына кергән тәкъдимнәрне, үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә киләсе составта:

1.Аброськина Антонина Николаевна - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге башлыгы.

2.Матягина Виктория Владимировна – Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары.

3.Михляева Елена Юрьевна – Күтәмә авыл җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече.

5. Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының эшче төркеменә, халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм авыл җирлеге Советы сессиясенә карауга кертергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Күтәмә авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе А.Н. Аброськина

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Советының 2020 елның19 мартындагы
158 номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 5статьяда:

1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 20 пунктча белән тулыландырырга: «20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдегең белән корылган корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документлар билгеләгән рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның иң чик параметрлары яки федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр нигезендә карар кабул итү».

1.2. 49 статьяда:

- 1 өлешнең 3 пунктына вәкаләтне өстәргә: «- Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдегең белән корылган корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру буенча документлар билгеләгән рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруның иң чик параметрлары яки федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр нигезендә карар кабул итә».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми хокукый порталда (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 87 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Күтәмә авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе А.Н. Аброськина

Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге Советының
2019 елның «19» мартындагы 158 номерлы
карарына 2нче кушымта

**ТӘРТИП**
**«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуларда гражданнарның катнашуы турында**

1. Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карары проекты буенча тәкъдимнәр Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423112, Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Күтәмә авылы, яки эл. почтага Kut.Cmn2@tatar.ru язма формада яисә кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| №/№ п/п | Мәкалә, бүлек, пункт, пунктча | Устав тексты | Уставка төзәтмәләр тексты | Төзәтмә исәпкә алынган проектның тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, телефон, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы турында» карары басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә, эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр стендка урнаштыру юлы белән кабул ителә.

2. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар эш көннәрендә 8дән 17 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү датасына 7 көннән дә соңга калмыйча түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Күтәмә авылы, Клуб ур., 1а йорт, шәхсән яки почта аша («Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлауларга» дигән тамгасы белән конвертта), шулай ук 4-30-88 телефоны буенча, шулай ук эл. почтага Kut.Cmn2@tatar.ru. Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарның тәкъдимнәре теркәлә һәм карау өчен авыл җирлеге Советының эшче комиссиясенә тапшырыла.

Чирмешән муниципаль
районы Күтәмә
авыл җирлеге Советының
2019 елның 19 мартындагы
158 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар (алга таба - гавами тыңлаулар) Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Уставы, әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Гавами тыңлауларда Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлегендә яшәүчеләр (алга таба - авыл халкы) үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән чыгыш ясыйлар, алар Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советына гавами тыңлаулар үткәрү датасына 7 көннән дә соңга калмыйча язмача гаризалар бирәләр.

3. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гариза бирмичә генә авыл җирлеге Советы депутатлары, авыл җирлеге Башлыгы, аның урынбасары, авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе, район прокуроры, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Чирмешән районындагы территориаль дәүләт хакимияте органнары һәм идарәсе вәкилләре чыгыш ясый.

4. Гавами тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

5. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

6. Гавами тыңлауларда авыл җирлеге Башлыгы яки аның кушуы буенча районның җирле үзидарә органының башка вазыйфаи заты рәислек итә.

7. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

8. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, күрсәтмәләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча гавами тыңлаулар секретариаты рәислек итүче һәм секретариатның ике әгъзасы составында сайлана.

9. Төп нотык белән авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет Регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе карары белән вәкаләтле авыл җирлеге Советы депутаты чыгыш ясый.

10. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

11. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау вакыты озайтылырга мөмкин, әмма 2 минуттан артыкка түгел.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы

13. Халык тыңлауларында катнашучылар ачык тыңлаулар барышын өзергә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Халык тыңлауларын үткәрү тәртибен бозган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

17. Халык тыңлауларында катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә бирелә һәм ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә.

18. Халык тыңлауларының беркетмәсенә рәислек итүче имза куя һәм ул авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

19. Халык тыңлаулары буенча йомгаклау авыл җирлеге Советының җирле үзидарә, Совет Регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халыкның куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясе белән әзерләнә.

20. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә стендта урнаштыру юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш

21. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү авыл җирлеге Советы аппараты һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан җирле бюджет хисабына башкарыла.